**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**
Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Азалак авыл җирлегенең Юлтимер авылы торак пунктында
2024 елда үзара салым кертү турында

**2023 елның 10 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлегенең Азалак авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге Юлтимер авылы торак пунктында “I нче группа инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәренән, көндезге бүлек студентларынан, хәрби хезмәт һәм контракт буенча узучы хезмәткәрләрдән, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, Азалак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1. Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- Юлтимер авылы урамнарнарын яктырту объектларын карап тоту һәм яктырту челтәрләрен ремонтлау (лампалар, таймерлар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

2. Юлтимер торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау:
- Юлтимер авылында кыш көне юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Юлтимер авылы территорияләрен җәй көне чабу (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- бензин чапкычлары, ГАЗ-САЗ-3512 автомашиналары һәм Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;
- Беларусь МТЗ-82.1 тракторына , ГАЗ-САЗ-3512 автомашиналары өчен запас частьләр сатып алу;
- Юлтимер авылы Яңа, Яшьләр,Үзәк,Тау урамнары буенча урамы буенча юлларны ремонтлау ( махсус техника арендалау, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, таш ташу һәм вак таш җәю, юл өслеген тигезләү);

3. Янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын төзү, ремонтлау:
- сулыкны төзекләндерү (махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

4. Традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү:
- Юлтимер авылы зираты территориясен киңәйтү, төзелеш материаллары сатып алу һәм койма кую өчен түләү;

5. Һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары булмаган (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү:

- Бөек Ватан сугышында һәләк булганнар исемлегенә төзәтмәләр кертү һәм яңарту.

6. Санкциясез чүплекләрне бетерү:

- Юлтимер авылы территориясендә көнкүреш калдыклары һәм чүп чар җыелу урыннарын чистарту (махсус техника арендалау, килешү буенча эшләр өчен түләү);

3. Әлеге карарны Азалак авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Азалак авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче: И.Г.Габдулгазизов